ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Большая Красная, 15/9, г. Казань,420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

Большая Красная ур., 15/9, Казан ш., 420111

тел/факс. 8 (843) 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№__140__

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«_15_» __11_ 2023_ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет турында» 21.12.2021 ел, №205 боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет турында» 21.12.2021 ел, №205 боерыгына (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 16.05.2022 ел, №81, 02.03.2023 ел, №27 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) (алга таба – боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерык преамбуласында «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алыштырырга;

бореык белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәдә:

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктта «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алыштырырга;

5.3 пунктның икенче кызыл юлын түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук ТР ДТИ инициативасы белән ТР ДТИ тарафыннан эшләнгән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында эшләнә торган, әлеге башкарма хакимият органнары карамагындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан фикер алышусыз кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар составын раслау турында» 2013 елның 29 мартындагы 214 номерлы карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарында эшләнә

торган норматив хокукый актлар һәм башка документлар исемлегендә каралган, әлеге башкарма хакимият органнары карамагындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан фикер алышусыз кабул ителә алмый торган норматив хокукый актларның проектларына һәм ТР ДТИ билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрелә торган норматив хокукый актларына Иҗтимагый совет бәяләмәсе бирү максатларында да үткәрелә.».

Җитәкче С.А. Крайнов